СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.04.2026 № 9/8

На №__________ от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 6 октябрендәге 13/5 номерлы карары белән кабул ителгән Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 567 номерлы Федераль законнар нигезендә муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 6 октябрендәге 13/5 номерлы карары (26.01.2022 № 17/3, 24.04.2023 № 32/8, 28.06.2024 № 47/5, 31.10.2025 № 2/4 карарлар редакциясендә) белән кабул ителгән Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.9.1 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) контрольдәге затларның, аларның вәкилләренең, үзе җайга салынучы оешма вәкилләренең булуына, әгәр контрольдәге зат өчен үзе җайга салынучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса, контроль чаралар уздырганда (контроль органнарның контрольдәге затлар белән үзара хезмәттәшлеге таләп ителми торган контроль чаралардан тыш) һәм һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законда каралган очракларда, контрольдәге затларның, аларның вәкилләренең ризалыгы белән Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең яки аның иҗтимагый вәкилләренең, Татарстан Республикасында

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең булуына каршылык күрсәтмәскә, консультацияләр бирергә.»;

1.2. 3.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Контроль органның вазыйфаи заты контрольдәге затларның һәм аларның вәкилләренең, шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән мөрәҗәгатьләре буенча консультацияләр бирә (муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә). Консультацияләр түләү алмыйча үткәрелә.»;

1.3. 3.5.2 пунктын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Косультация бирү контроль органның вазыйфаи заты тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән, шәхси кабул итүдә яисә профилактик чара, контроль чара үткәрү барышында башкарылырга мөмкин.»;

1.4. VI бүлекнең 6.4 пункты икенче абзацын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:

«Контроль органы күрсәтмәсенә шикаять контрольдәге зат күрсәтмә алган вакыттан алып ун эш көне эчендә, шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин. Шикаять бирү срогы нигезле сәбәпләр аркасында узып киткән очракта, шикаять бирүче затның үтенече буенча бу срок вәкаләтле орган тарафыннан кире торгызылырга мөмкин.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http:tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев